**Татарстан Республикасы Азнакай районы**
**Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 245-27 «25» октябрь 2023 ел

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контроле турында нигезләмә хакында» 2021 елның 29 сентябрендәге 80-10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (25.02.2022 №117-15, 08.06.2023 №230-25 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контроле турында нигезләмә хакында» 2021 елның 29 сентябрендәге 80-10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәгә (25.02.2022 №117-15 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымтаны, әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карарына 1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда контроль чаралар уздыру өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары

1. Муниципаль торак контроле органы адресына гражданнардан кергән (мөрәҗәгать иткән гражданның шәхесен ачыкларга мөмкинлек биргән ысул) һәм күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре булган оешмаларның, дәүләт хакимияте, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән алынган мөрәҗәгатьләр санының өч мәртәбә һәм аннан да күбрәк үсеше, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозуның фактлары турында дәүләт мәгълүмат системалары хакында.
2. Көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча хәл ителгән муниципаль торак фондының торак урыннары булган күпфатирлы йортта урыннар милекчеләренең гомуми җыелышының өч ай рәттән ике һәм аннан да күбрәк беркетмәләре муниципаль торак контроле органына керү.